КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 гыйнвар г.Казань № 41

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 138 нче; 2018 ел, 2 апрель, 200 нче; 2018 ел, 5 июнь, 425 нче; 2018 ел, 4 июль, 550 нче; 2018 ел, 8 декабрь, 1090 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 пунктындагы икенче абзацка «ачык грунт яшелчәләре» сүзләреннән соң «, техник киндер» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә үсемлекчелек өлкәсендә, орлык бәрәңге, ачык грунт яшелчәләре һәм озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

Тәртип исеменә «ачык грунт яшелчәләре» сүзләреннән соң «, техник киндер» сүзләрен өстәргә;

1 нче пунктта:

«а» пунктчасына «чыгымнарның бер өлешен каплауга» сүзләре алдына «өстәлгән бәягә салым исәпкә алынмаган (алга таба – ӨБС исәпкә алынмаган)» сүзләрен өстәргә;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) орлык бәрәңге һәм ачык грунт яшелчәләрен җитештерүне үстерү өлкәсендә Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан

расланган исемлек нигезендә орлык бәрәңге, ачык грунт яшелчәләре, техник киндер һәм озын сүсле җитен җитештерүне арттыруны тәэмин итә торган агротехнология эшләре комплексын үткәрүгә ӨБС исәпкә алынмаган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен чәчү мәйданының 1 гектары исәбеннән чыгып файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә (алга таба – орлык бәрәңге, ачык грунт яшелчәләре, техник киндер һәм озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә ярдәм күрсәтү).»;

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Үсемлекчелек өлкәсендә ярдәм күрсәтү өчен аның алучысына бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = PJ \times S_{зкк} \times 0,7 + PJ \times S_{зкк} \times K_{пп} \times 0,15 + P_{стр} \times S_{зкк} \times 0,15,$$

монда:

W – үсемлекчелек өлкәсендә ярдәм күрсәтү өчен алучыга бирелә торган субсидия күләме, сумда;

PJ – агымдагы финанс елында алучының бөртекле ашлык, бөртекле-кузаклы ашлык һәм авыл хуҗалыгы азык культуралары биләгән чәчү мәйданы, гектарда;

$S_{зкк}$ – ашлык, бөртекле-кузаклы ашлык һәм авыл хуҗалыгы азык культуралары биләгән чәчү мәйданының 1 гектары өчен Министрлык боерыгы белән раслана һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә торган субсидия ставкасы, сум:

$$S_{зкк} = R \times \frac{0,88}{P},$$

монда:

R – үсемлекчелек өлкәсендә, орлык бәрәңге, ачык грунт яшелчәләре һәм озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтү өчен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре күләме, сумда;

P – агымдагы финанс елында алучының бөртекле ашлык, бөртекле-кузаклы ашлык һәм авыл хуҗалыгы азык культуралары биләгән чәчү мәйданы, гектарда;

$K_{пп}$ – Татарстан Республикасының муниципаль районы буенча исәпләп чыгарылган, «Татар» агрохимия хезмәте үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе һәм «Әлмәт» агрохимия хезмәте станциясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан бирелгән мәгълүматлар нигезендә билгеләнгән, Министрлык боерыгы белән раслана торган агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата туфракның уңдырышлылыгы коэффициенты;

$P_{стр}$ – агымдагы финанс елында авыл хуҗалыгы культуралары уңышын иминләштерү шартнамәсе (шартнамәләре) белән расланган авыл хуҗалыгы культураларының иминләштерелгән мәйданы, гектарда.»;

6 нчы пунктта:

беренче абзацка «һәм (яки) озын сүсле җитен» сүзләреннән соң «, техник киндер» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацка «, техник киндер» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацка «һәм (яки) озын сүсле җитен» сүзләреннән соң «, техник киндер» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацка «һәм (яки) озын сүсле җитен» сүзләреннән соң «, техник киндер» сүзләрен өстәргә;

тугызынчы абзацта «озын сүсле җитен» сүзләреннән соң «, техник киндер» сүзләрен өстәргә;

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Ачык грунт яшелчәләрен җитештерүне үстерү өлкәсендә ярдәм күрсәтү өчен алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = P_{тг} \times S,$$

монда:

W – ачык грунт яшелчәләрен җитештерүне үстерү өлкәсендә ярдәм күрсәтү өчен алучыга бирелә торган субсидия күләме, сумда;

$P_{тг}$ – агымдагы финанс елында алучының ачык грунт яшелчәләре биләгән чәчү мәйданы, гектарда;

S – 1 гектарга 10,0 мең сум исәбеннән субсидия ставкасы.»;

9 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«агымдагы финанс елына авыл хуҗалыгы культуралары уңышын иминләштерү шартнамәсен (шартнамәләрен);

исәпләнгән иминият премиясенең кимендә яртысын түләү өчен түләү йөкләмәсен.»;

10 нчы пунктта:

«а» пунктчасының унынчы абзацына «федераль» сүзеннән соң «дәүләт» сүзен өстәргә;

«б» пунктчасының беренче абзацына «, техник киндер» сүзләрен өстәргә;

«б» пунктчасының икенче абзацына «җитеннең» сүзеннән соң «һәм техник киндернең» сүзләрен өстәргә;

12 нче пунктның икенче абзацында «нумерланырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиеш булган журналда» сүзләрен «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидияләү» электрон гаризалар теркәү системасында» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә затлы орлыкчылыкны үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

1 нче пунктка «чыгымнарның бер өлешен каплауга» сүзләре алдына «өстәлгән бәягә салым исәпкә алынмаган» сүзләрен өстәргә;

6 нчы пунктта:

алтынчы абзацта «Министрлык боерыгы белән раслана» сүзләрен төшереп калдырырга;

җиденче абзацта «30» саннарын «40» саннарына алыштырырга;

8 нче пунктның икенче абзацында «нумерланырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиеш булган журналда» сүзләрен «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидияләү» электрон гаризалар теркәү системасында» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә күпьеллык үсентеләр үстерүдә булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу Тәртип агымдагы финанс елында күпьеллык утыртмаларны утырту һәм карап үстерү өчен авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләре тарафыннан күрелгән һәм өстәлгән бәягә салым исәпкә алынмаган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен, шулай ук хисап финанс елында күрелгән һәм өстәлгән бәягә салым исәпкә алынмаган әлеге чыгымнарны каплау өчен хисап финанс елында тиешле субсидия бирелмәгән очракта хисап финанс елында авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр (алга таба шул ук эзлеклелектә – күпьеллык үсентеләр, алучылар, субсидияләр) бирү механизмын билгели.»;

5 нче пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«S – күпьеллык утыртмалар биләгән 1 гектар мәйданга әлеге утыртмаларны утырту чыгымнарының 70 проценты күләмендә (куак-җиләк утыртмалары һәм классик типтагы орлыктан үстерелгән терәксез бакчалар буенча – 1 гектарга иң күбе 100,0 мең сум, 1 гектарга 800 данәдән алып 1199 данәгә кадәр агачлар урнашу тыгызлыгы белән интенсив типтагы бакчалар буенча – 1 гектарга иң күбе 300,0 мең сум, 1 гектарга 1200 данәдән күбрәк агачлар урнашу тыгызлыгы белән интенсив типтагы бакчалар буенча – 1 гектарга иң күбе 500,0 мең сум) субсидия ставкасы.»;

6 нчы пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$S_{ух}$ – күпьеллык утыртмалар биләгән 1 гектар мәйданга әлеге утыртмаларны карап үстерү чыгымнарының 30 проценты күләмендә (1 гектарга иң күбе 15,0 мең сум) субсидия ставкасы.»;

7 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«күпьеллык утыртмалар посадкалары биләгән җир кишәрлекләренә хокук билгеләүче документлар күчермәсен;

күпьеллык утыртмалар үсентеләренә яраклылык сертификатын.»;

8 нче пунктның икенче абзацында «нумерланырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиеш булган журналда» сүзләрен «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидияләү» электрон гаризалар теркәү системасында» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сөтле терлекчелектә продуктивлыкны арттыруга юнәлдерелгән субсидияләр бирү тәртибендә:

1 нче пунктка «чыгымнарның бер өлешен каплауга» сүзләре алдына «өстәлгән бәягә салым исәпкә алынмаган» сүзләрен өстәргә;

9 нчы пунктның икенче абзацында «нумерланырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиеш булган журналда» сүзләрен «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидияләү» электрон гаризалар теркәү системасында» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы

бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

1 нче пунктка «чыгымнарның бер өлешен каплауга» сүзләре алдына «өстәлгән бәягә салым исәпкә алынмаган» сүзләрен өстәргә;

5 нче пунктның «в» пунктчасында «35» саннарын «40» саннарына алыштырырга;

12 нче пунктның икенче абзацында «нумерланырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиеш булган журналда» сүзләрен «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидияләү» электрон гаризалар теркәү системасында» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сарык һәм кәҗәләрнең ана башларын саклау һәм үрчетү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

1 нче пунктка «чыгымнарның бер өлешен каплауга» сүзләре алдына «өстәлгән бәягә салым исәпкә алынмаган» сүзләрен өстәргә;

7 нче пунктның икенче абзацында «нумерланырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиеш булган журналда» сүзләрен «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидияләү» электрон гаризалар теркәү системасында» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә агросәнәгать комплексы объектларын төзү һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

1 нче пунктта «чыгымнарның бер өлешен каплауга» сүзләре алдына «өстәлгән бәягә салым исәпкә алынмаган» сүзләрен өстәргә;

8 нче пунктның икенче абзацында «нумерланырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиеш булган журналда» сүзләрен «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидияләү» электрон гаризалар теркәү системасында» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә культуртехника, урман агромелиорациясе һәм гидромелиорация чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

1 нче пунктта:

беренче абзацта «чыгымнарның бер өлешен каплауга» сүзләре алдына «өстәлгән бәягә салым исәпкә алынмаган» сүзләрен өстәргә;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) гомуми һәм индивидуаль файдаланудагы сугару һәм киптерү системаларын һәм аерым урнашкан гидротехник корылмаларны, шулай ук алучылар милек (аренда) хокукында ия булган балык үрчетү буаларын төзү, реконструкцияләү, техник яңадан җиһазландыру буенча гидромелиорация чараларын, шулай ук төзү, реконструкцияләү һәм техник яңадан җиһазландыру кыйммәтенең җыелма смета исәп-хисабына кертелгән (шул исәптән лизингка сатып алынган) машиналар, җайланмалар, яңгыр һәм су сиптерү аппаратлары, насос станцияләре (алга таба – объектлар) сатып алуга (әлеге объектларга карата проект

һәм эзләнү эшләрен үткәрүгә һәм (яки) проект документларын әзерләүгә бәйле чыгымнардан тыш).»;

11 нче пунктның икенче абзацында «нумерланырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиеш булган журналда» сүзләрен «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидияләү» электрон гаризалар теркәү системасында» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Эшләрен башлап җибәрүче фермерларга дәүләт ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган грантлар бирү тәртибендә:

5.3.11 нче пунктка «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

5.9 нчы пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.9. Конкурс комиссиясе 30 көн эчендә тапшырылган документларны карап тикшерә, конкурста катнашучылар исемлеген төзи, кертелгән бизнес-планнарны Нигезләмә нигезендә бәяли, конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен рәсмиләштереп, крестьян-фермер хуҗалыклары башлыклары белән йөзгә-йөз әңгәмә үткәрә һәм конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләрне билгели. Гариза бирүче бу карарның 5.3 нче пунктында күрсәтелгән документлар пакетын тулысынча тапшырмаган очракта, конкурс комиссиясе гариза бирүченең гаризасын йөзгә-йөз әңгәмә барышында кабул итми.»;

6.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Грант күләме Министрлык тарафыннан крестьян-фермер хуҗалыгының үз акчасын һәм аның чыгымнар планын исәпкә алып билгеләнә.

Ит яки сөт юнәлешләрендәге мөгезле эре терлек үрчетү өчен грантның максималь күләме – иң күбе 3,0 млн.сум, әмма чыгымнар планында күрсәтелгән һәм өстәлгән бәягә салым исәпкә алынмаган чыгымнарның иң күбе 90 процентын, эшчәнлекнең башка төрләрен алып бару өчен иң күбе 1,5 млн.сум, әмма чыгымнар планында күрсәтелгән һәм өстәлгән бәягә салым исәпкә алынмаган чыгымнарның иң күбе 90 процентын тәшкил итә.»;

әлеге карар белән расланган Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган грантлар бирү тәртибендә:

2.1.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.4. Крестьян-фермер хуҗалыгы башлыгы һәм әгъзалары эшләрен башлап җибәрүче фермерлар өчен грантлар һәм гаилә терлекчелек фермаларын үстерү өчен грант элегрәк алмаган йә гаилә фермалары һәм эшләрен башлап җибәрүче фермерлар өчен грантны тулысынча үзләштергән көннән кимендә өч ел вакыт узган һәм үткән проект буенча авыл хуҗалыгы терлекләренең баш санын һәм оештырылган даими эш урыннарын киләсе проект буенча йөкләмәләрнең кимендә чыгу вакытына кадәр саклап калу шарты белән. Шул ук вакытта бер үк чыгымнарны грант исәбеннән финанслау рөхсәт ителми;»;

3.3.7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.7. Гаилә терлекчелек фермасын үстерү өчен грант крестьян-фермер хуҗалыгына грант үзләштерелгәннән соң өч ел үткәч һәм үткән проект буенча авыл хуҗалыгы терлекләренең баш санын һәм оештырылган даими эш урыннарын киләсе проект буенча йөкләмәләрнең кимендә чыгу вакытына кадәр саклап калу шарты белән яңадан бирелергә мөмкин.»;

5.3.15 нче пунктка «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

5.3.18 нче пунктка «РСВ-1 ПФР» сүзләреннән соң «яки СЗВ-М» сүзләрен өстәргә;

5.8 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Гариза бирүче бу карарның 5.3 нче пунктында күрсәтелгән документлар пакетын тулысынча тапшырмаган очракта, конкурс комиссиясе гариза бирүченең гаризасын йөзгә-йөз әңгәмә барышында кабул итми.»;

6.1 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ит яки сөт юнәлешләрендәге мөгезле эре терлек үрчетү өчен грантның максималь күләме – 1 хуҗалыкка иң күбе 30,0 млн.сум, әмма чыгымнар планында күрсәтелгән һәм өстәлгән бәягә салым исәпкә алынмаган чыгымнарның иң күбе 60 процентын, авыл хуҗалыгы хайваннарының башка төрләрен, кош-корт һәм балык үрчетү һәм карап үстерү өчен – бер хуҗалыкка 20,0 млн.сумнан артмаган күләмдә, әмма чыгымнар планында күрсәтелгән һәм өстәлгән бәягә салым исәпкә алынмаган чыгымнарның иң күбе 60 процентын тәшкил итә.»;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган грантлар бирү тәртибенең 6.1 нче пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Грантның максималь күләме бер кооперативка иң күбе 70,0 млн.сум һәм Чыгымнар планында күрсәтелгән һәм өстәлгән бәягә салым исәпкә алынмаган чыгымнарның иң күбе 60 проценты күләмендә тәшкил итә.»;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә үсемлекчелек һәм терлекчелек тармакларын үстерүнең максатчан күрсәткечләренә ирешүгә булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

1 нче пунктка «чыгымнарның бер өлешен каплауга» сүзләре алдына «өстәлгән бәягә салым исәпкә алынмаган» сүзләрен өстәргә;

7 нче пунктның икенче абзацында «нумерланырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиеш булган журналда» сүзләрен «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидияләү» электрон гаризалар теркәү системасында» сүзләренә алыштырырга;

5 нче пунктта:

бишенче абзацта «хисап» сүзен «агымдагы» сүзенә алыштырырга;

тугызынчы абзацта «хисап» сүзен «агымдагы» сүзенә алыштырырга;

унынчы абзацта «хисап» сүзен «агымдагы» сүзенә алыштырырга;

6 нчы пунктның тугызынчы абзацында «хисап» сүзен «агымдагы» сүзенә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин